МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.08.2023 Казан ш № 661

«Сиделка» хезмәте кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәтләр күрсәтүнең максималь вакыт нормаларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021-2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру кысаларында «Сиделка» хезмәтен күрсәтү буенча проектны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 елның 13 февралендәге 77 номерлы карары белән расланган 2021-2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру кысаларында «Сиделка» хезмәтен күрсәтү буенча проектны гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 7.1 пунктын гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

«Сиделка» хезмәте кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәтләр күрсәтүнең максималь вакыт нормаларын расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2023 елның
«07» августындагы 661 номерлы
боерыгы белән расланды

«Сиделка» хезмәте кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәтләр күрсәтү вакытының максималь нормалары

| Тәртип саны | Социаль хезмәтнең аталышы | «Сиделка» хезмәте кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәтләр күрсәтү вакытының максималь нормасы (1 хезмәт күрсәтү), минут |
|---|---|---|
| 1. | Ризык әзерләү | 60 |
| 2. | Ашарга (ашатырга) ярдәм итү | 45 |
| 3. | Гигиена хезмәтләре күрсәтү: | |
| 3.1. | кул тырнакларын кисү | 10 |
| 3.2. | аяк тырнакларын кисү | 40 |
| 4. | Санитар-гигиена процедураларын күрсәтү (чәч тарау, юынырга ярдәм итү, тешләрне яки казналыкны карау, авыз куышлыгын чистарту, социаль хезмәт күрсәтелә торган ир-ат җенесендәге затларны кырындыру) | 15 |
| 5. | Юындыру (юынганда ярдәм күрсәтү): | |
| 5.1. | урын өстендә тулысынча коендыру | 50 |
| 5.2. | душ яки ванна бүлмәсендә тулысынча коендыру | 40 |
| 5.3. | тәнне өлешчә бәдрәф кылу | 29 |
| 6. | Бәдрәфтән (савыттан) файдаланганда ярдәм итү | 10 |
| 7. | Урын-җирне алыштыру: | |
| 7.1. | тәндәге | 15 |
| 7.2. | урын-җир | 15 |

| | | |
|---|---|---|
| 8. | Караватта позицияләү | 7 |
| 9. | Сәламәтлек торышындагы тайпылышларны ачыклау максатыннан социаль хезмәтләр алучыларны системалы күзәтү (шул исәптән табиб билгеләве буенча тормыш эшчәнлегенең төп күрсәткечләрен (тән температурасы, артериаль басым) үлчәүдә ярдәм итү) | 10 |
| 10. | Социаль-тернәкләндерү чараларын үткәрү | 45 |